# Методик кулланма

**Кереш**

Рәсем сәнгате мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүдә, аларга белем бирүдә мөһим роль уйный. Ул эстетик карашны формалаштыруга, күз алдына китерү һәм танып белү сәләтен үстерүгә, эмоциональлекне үстерүгә ярдәм итә. Татарстан Республикасы рәссамнарының бу төбәк мәдәниятен, аның табигатен һәм гореф-гадәтләрен чагылдырган картиналары мәктәпкәчә учреждениеләрнең белем бирү эшчәнлегендә бәһасез чара булып тора.

Әлеге кулланма Татарстан рәссамнары картиналарын балалар белән эшләгәндә файдалануга бәйле методик киңәшләр тәкъдим итә.

**1. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә картиналардан файдалануның максатлары һәм бурычлары**

Максат:

– Балаларны Татарстан Республикасының сәнгати мирасы белән таныштыру.
– Эстетик күзаллау сәләтен һәм сәнгати зәвыкны үстерү.
– Рәсем сәнгатенә карата кызыксыну формалаштыру.
– Сөйләмне, күзаллау һәм эмоциональ тоемлау сәләтен үстерү.

Бурыч:

– Балаларны Татарстан рәссамнары иҗаты белән таныштыру.
– Картиналарны анализларга һәм тасвирлап бирергә өйрәтү.
– Картиналарны иҗади сәләтләрне үстерү чарасы буларак куллану.
– Туган як мәдәниятенә һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияләү.

**2. Картиналар белән эшләү методикасы**

2.1. Картиналар сайлап алу

Мәктәпкәчә балалар белән эшләү өчен түбәндәге таләпләргә туры килгән картиналар сайларга тәкъдим ителә:

– Сюжет ягыннан аңлаешлы, хәтергә калырлык.
– Татарстанның табигатен, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен чагылдыра торган.
– Балаларда хис-тойгы уята торган.

Рәссамнар һәм аларның кайбер эшләренә мисаллар:

Бакый Урманче – «Урал тау итәгендә», «Гани Сафиуллин портреты» картиналары.

Харис Якупов – Бөек Ватан сугышына багышланган эшләр, мәсәлән, «Девятаев портреты».

Равил Заһидуллин – Татарстан тарихына, йолаларга һәм гореф-гадәтләргә багышланган эшләр: «Казан урамнарында», «Сабан туе алдыннан бүләк җыю».

Айрат Гайфуллин – Казанны сурәтләнгән картиналар, мәсәлән, «Казан университеты».

2.2. Картина белән эш этаплары

Картина белән танышу:

– Картинаны балалар белән бергәләп карагыз.
– Сораулар бирегез: «Картинада нәрсә сурәтләнгән?», «Рәссам нинди төсләрне кулланган?», «Картинаны нинди хис уята?».

Рәссам турында әңгәмә:

– Рәссамның кыскача биографиясен сөйләп бирегез.
– Аның ни өчен үз эшләре өчен шундый темалар сайлаганн аңлатыгыз.

Картинаны тасвирлау:

– Балаларга картинада нәрсә күрүләрен (табигать, кешеләр, предметлар) сөйләп бирергә тәкъдим итегез.
– Детальләргә; төсләр, яктылык, композициягә игътибар юнәлтегез.

Хис-тойгы уяту:

– Картинаның нинди хисләр китереп чыгаруын сорагыз.

– Балаларга үзләрен картинада сурәтләнгән урында, хәлдә күз алдына китереп карарга тәкъдим итегез.

Иҗади эшчәнлек:

– Балаларга картинаның үз версияләрен ясарга тәкъдим итегез.

– Әсәр мотивлары буенча әвәләү яки аппликация шөгыле оештырыгыз.

3. Балалар бакчасы эшчәнлегендә картиналарны куллану үрнәкләре. Картинаны тасвирлау һәм рәссам турында мәгълүмат бирү үрнәкләре.

3.1. Шамил Якуповның «Хатирәләр» картинасы.

Рәссам Шамил Камил улы Якупов 1956 елның 25 гыйнварында Кукмара районының Адай авылында туган. Казан сәнгать училищесында укыган. Рәссамның әсәрләре Татарстан Республикасының дәүләт музейлары һәм галереялары тупланмаларында, шулай ук шәхси коллекцияләрдә урын алган.

Картинада агач йорт фонында балан куагы булган карлы кышкы манзара сурәтләнгән.

Картинаның композициясе балан тәлгәшләре һәм кар белән бизәлгән куак ботаклары нигезендә төзелгән. Алгы планда кар каплаган койма күренә. Картинаның үзәгендә ак рамлы тәрәзә урын алган. Балан ботакларында карабүрекләргә охшаган ике кош утыра, алар җимеш чукырга килгән. Картинаның аскы уң почмагында аклы-каралы мәче күренә. Бөтен картина җылы тоннарда ясалган һәм кышкы тынлык, рәхәтлек тойгысы уята.

Рәссам майлы буяу белән рәсем ясау техникасын кулланган. Ул буяуларны тигез итеп төшергән, төсләр балансын сайлауны бик тырышып башкарган. Төсләр палитрасы нигездә кызыл, аксыл көрән, соры һәм ак төсләрдән тора. Буяу эзләрендә җиңелчә штрихлар сизелә.

Бу картинаны кулланып уздырыла торган шөгыль тәртибе:

– Балаларга картина күрсәтергә һәм аларның рәсемдә нәрсә күрүләре турында сөйләп бирергә тәкъдим итәргә.

– Бу картинаның нинди хисләр уятуы, ни өчен кыш фасылының тынлык, тынычлык белән ассоциацияләнүе турында фикер алышырга.

– Балаларга, рәсем ясауның төрле техникасын кулланып, кыш рәсемен ясарга тәкъдим итәргә.

3.2. Равил Заһидуллинның «Мунчадан соң чәй эчү» картинасы

Картинаны тасвирлап бирү:

Картинада агач йорт, бабай һәм малай сурәтләнгән. Җәйге көн. Бабай белән малай мунчадан соң чәй эчәләр…

Әңгәмә:

Татар авылларындагы тормыш-көнкүреш, йолалар һәм гореф-гадәтләр турында сөйләгез.

Практик шөгыль:

Балаларга авыл рәсеме ясарга яки «Татар стилендәге йорт» дигән эшләнмә ясап алып килергә тәкъдим итегез.

3.3. Лотфулла Фәттаховның «Сабан туе», Илдус Мортазинның «Бәйрәм» картиналары

Картиналарны тасвирлап бирү:

Картиналарда биюләре, көрәш бзйгесе һәм уеннары булган халык бәйрәме сурәтләнгән.

Әңгәмә:

Сабан туе бәйрәме, аның татар халкы өчен әһәмияте турында сөйләгез.

Практик шөгыль:

Төркемдә җыр-биюле, уенлы кечкенә бәйрәм оештырыгыз.

4. Картиналарны педагогик эшчәнлекнең төрле төрләрендә куллану

4.1. Сөйләм үстерү шөгыльләре (картинаны тасвирлау, хикәяләр төзү).
4.2. Музыка шөгыльләре (картинадан тәэсирләнеп музыкаль композицияләр тыңлау).
4.3. Физкультура шөгыльләре (картина персонажларының хәрәкәтләрен имитацияләү).
4.4 Экологик шөгыльләр (табигатьне пейзажлар нигезендә өйрәнү).
4.5. Күргәзмәләр һәм конкурслар оештыру
4.5.1. Төркемдә мини-күргәзмәләр уздыру.
4.5.2. Картина мотивлары буенча рәсем конкурсларында катнашу.
4.5.3. Ата-аналарның һәм балаларның бергә иҗат эшчәнлеге.